ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Әни юллап тапкан шиферлар инде бу. Әйбәтләп куйсаң, тагын әллә ничә ел утырырлар әле»

> 2

КАЙТ, БАЛАМ!
Балаларның өйдән качу сәбәпләрен атадылар

> 2



МӘСКӘҮНЕ ШАККАТЫРГАН
Казан кызы Карина Мотыйгуллина мәктәп программасын үзгәртергә тәкъдим итә

> 4

ТАРИХКА СӘЯХӘТ
«Көмеш дага» маршруты Бишбалта бистәсенең без белмәгән якларын ача

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 74 (29041) | Шимбә | 27 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ШИКӘРДӘН БАЛ АКМЫЙ

Хәләл сыр, татар балы һәм тал бишек. Россия эшмәкәрлек көне уңаеннан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республика эшкуарлары белән очрашты. «Без сезнең белән бергә һәм һәрвакыт ярдәм итәргә тырышачакбыз», – диде ул, алдан ук чарага җылы төсмер биреп. Монысы беткәнче үк, киләсе очрашу вакытын да билгеләде.

Рөстәм Миңнеханов чарага әзерләнеп килгән.

– Программаны иртән карап чыккан идем. Нәрсә, без бүген уңышлар турында гына сөйләшәбезме әллә? – дип, алып баручыларга мөрәҗәгать итте ул.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, гел уңышлар турында гына сөйләшеп утыру дөрес түгел.

– Уңышсызлыклар турында да әйтергә кирәк. Башкалар моннан гыйбрәт алсын. Эшмәкәрнең эше уңмаса да, ул яңадан торып басып, алга атлый белергә тиеш. Эшмәкәрлек ул – бик зур җаваплылык. Эшкуар башкаларны эшле итә, аларга хезмәт хакы түли, кредит ала, дәүләт белән эшлекле мөнәсәбәтләр кора, – диде ул. – Без иң беренче чиратта тармактагы проблемалар турында ишетергә тиеш. Әгәр аларны күрүдән, ишетүдән туктасак, алга атлау тизлеге акрынаячак.

Рәис, залда утыручы эшмәкәрләргә мөрәҗәгать итеп:

– Әлеге чарада чыгыш ясарга тиеш булмасагыз да, үз сүзегезне әйтә аласыз. Без сезне борчыган мәсьәләләр турында белергә телибез, – диде.

Чара ахырында иң өлгер эшмәкәрләр әлеге мөмкинлектән файдаланды да. Тик бу хакта соңрак.

– Ярар, бу юлы мактауга корылган чараның тәртибен бозмыйк. Бәйрәм уңаеннан кәефне бозарга теләмәгәннәрдер, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Яхшыдан да үрнәк алып була анысы. «Ике ел чамасы элек аш бүлмәсендә башланган эшебезне бүген ил күләмендә беләләр», – дип сөйләде әнә «Воронцов сырлары» хуҗасы. Аена 4 тонна сыйфатлы сөт ризыклары җитештерүләре, мәсәлән, кара сыр һәм әлеге төр продукциянең чит илнеке белән бер дәрәҗәдә булуын да әйтте ул.

– Хак сөйләмисең. Бер дәрәҗәдә түгел, ә без чит илләрне күптән уздырдык дияргә кирәк. Дөресе шул, – дип үсендереп җибәрде эшмәкәрне Рәис.

Сыр җитештерү өчен сөтнең 90 процентын республика хуҗалыкларыннан алалар икән. Татарстанда әлеге сан 100 процент та була алуына ишарәләпме, «Кемнәрдән?» – дип тә кызыксынды Рөстәм Миңнеханов. Баксаң, җитештерү өчен кирәкле сыер һәм кәҗә сөтен республикадан алалар, ә сарык сөтен, бездә булмаганга күрә, Мәскәү өлкәсеннән кайтарталар. Рәис эшмәкәргә чит ил базарларына чыгу өчен, хәләл сыр җитештерә башлау мәсьәләсен дә өйрәнергә киңәш итте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ә менә «Татар балы» бренды дөнья базарына якын арада ук чыгачак дип сөендерделәр очрашуда.

– Республикада былтыр товар буларак 5,5 мең тонна бал суыртканнар. Ни кызганыч, умартачыларның авыр хезмәте тиешенчә бәяләнми. Татарстанда балны күпләп сатып алу бәясе түбән, – дип сөйләде «Татар балы» кооперативы хуҗасы Язил Муллахаҗиев. – Без былтыр Кукмарада бал эшкәртү цехын ачып җибәрдек. Республика күләмендә балны җыеп эшкәртү һәм күпләп сату белән шөгыльләнәбез. Бүгенге көндә 20 төрдән артык продукция җитештерәбез. Әмма балны лаеклы бәядән сатып булмый. Кибетләр аны бездән килосын якынча 130 сумнан сатып ала. Шуңа күрә дә умартачылардан балны кабул итү бәясе 80–90 сум тирәсендә тирбәлә. Ә бу умарта тотучыларга отышлы түгел. Шуңа күрә дә суырткан балларының яртысын бүләккә өләшеп бетерәләр.

Бүген Татарстаннан бер кило бал да экспортка чыгарылмый икән. Югыйсә «Башкортстан балы»н бөтен дөнья белә.

– Безнең бал да күршеләрнекеннән калышмый. Башкортстан инде күптән Татарстанның чиктәш Әгерҗе, Актаныш кебек районнарыннан күпләп бал сатып алып, аны үзенеке итеп сата. Моңа чик куеп, «Татар балы»н бөтен дөньяга танытырга телибез. Безнең цехта елына 3,5 мең тоннага кадәр продукция эшкәртү мөмкинлеге бар. Казанда узган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum»да Казахстан белән бал озата башлауга бәйле тәүге килешү төзедек. Безнең исәпләүләр буенча, чит илгә балны килосын 220 сумнан сатарга мөмкин. Ә бу аны үзебездә калдыруга караганда икеләтә отышлырак, – диде Язил Муллахаҗиев.

Рөстәм Миңнеханов эшмәкәргә сыйфат турында онытмаска да киңәш итте.

– Умарта алдына шикәр куеп бал агызмыйлар, – диде ул.

Ике сәгатькә якын дәвам иткән очрашуда республика эшкуарларына сәүдә үзәкләрендә урыннар булдыру, талдан үреп җиһаз ясау кебек югалган кәсепләр өчен белгечләр әзерләү кебек мәсьәләләр буенча да фикер алыштылар. Рөстәм Миңнехановка республиканың барлык эшмәкәрләрен һәм үзмәшгульләрен бер канат астына алган «Мин бит инде ул – Татарстан» брендын да тәкъдим иттеләр. Россия эшмәкәрлек көне уңаеннан, чаралар көн буена сузылган булса да, Рәис залда утыручы берничә эшмәкәрне тыңлады. Мәсәлән, Диләрә Хөснетдинова абыйсы һәм әтисе катнашында төзегән компаниядә дистә елдан артык икмәк ризыклары һәм тавык ите эшкәртү белән шөгыльләнә. Эшне тагын да җәелдерергә телиләр. Ә моның өчен зур суммада акча кирәк. Шуңа күрә дә Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина белән очрашып сөйләшмәкчеләр.

– Ике айдан бирле җитәкчегә эләгә алмыйбыз. Бөтен өмет сездә, – дип мөрәҗәгать итте эшмәкәр Рөстәм Миңнехановка.

Бәхеткә, Талия Миңнуллина залда ук булып чыкты. Рөстәм Миңнеханов Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенә эшмәкәрне кабул итәргә, соңрак очрашу нәтиҗәләре турында хисап тотарга кушты. Гүзәл затлар чарадан соң ук сөйләшеп утыра иде инде. Башкаларны да ишетәчәкләр. Рөстәм Миңнеханов бер ай – ай ярым эчендә яңадан эшмәкәрләр белән очрашырга сүз бирде.

Сан

Рәсми саннарга караганда, Татарстанда эш урыннарының **40** проценты кече һәм урта бизнеска туры килә. Былтыр аларга якынча **85** миллиард сумлык ярдәм күрсәтелгән. **2022** ел нәтиҗәләре буенча, республикада **234** мең үзмәшгуль бар.

Кызу эш өсте

Мәскәү белән Казанны тоташтырачак М12 юлы өчен Татарстанда Идел аша күпер салучылар тәүлек әйләнәсе эшли. Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин әйтүенчә, сентябрь азагында төзүчеләр күпергә тәүге асфальтбетон түшәмәсе салырга ниятли.

Россия Хөкүмәте матбугат хезмәте хәбәренә караганда, Идел күпере яңа юлдагы иң озын күпер (3,36 чакрым) булачак. Бүгенгә 28 терәгенең 26сы әзер икән инде.

Хәзерге вакытта Идел аша күпер салуга гына да 1 меңләп кеше һәм 300 берәмлек техника җәлеп ителгән. Мәскәүдән Казанга кадәрге автомобиль магистрален ел азагына ачу ниятләнә.

4 миллионнан артканбыз

Узган ел йомгаклары буенча, Татарстанда яшәүчеләр саны 4 миллионнан артып киткән. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, соңгы елда республикага рәсми төстә 115 меңнән артык кеше өстәлгән. Кайбер районнарда халык саны 20 проценттан күбрәккә арткан. Белгечләр әйтүенчә, Татарстан икътисадының нык үсүе сәбәпле, мигрантларны да күп җәлеп итә.

Рәсми статистика буенча, ел башына төбәгебездә 4,002 миллион кеше яшәгән. Шул ук вакытта туучылар саны кимү теркәлгән. Узган елда Татарстанда 36,7 мең бала туган, 48,8 мең кеше вафат булган.

Татарстанның 25 районында халык саны арткан, 20 районында кимегән. Питрәч районыннан тыш, барлык районнарда туучыларның үлүчеләргә караганда кимрәк булуы күзәтелә. Казанда һәм Чаллыда гына туучыларның берникадәр артуы теркәлгән.

Чирләр чигендә

Соңгы биш айда Татарстанда кызамык авыруының 61 очрагы теркәлгән. Бу хакта Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина матбугат очрашуында хәбәр итте.

Роспотребнадзор белгече әйтүенчә, 61 очракның 26сы балаларга туры килә. Чир йоктырган 31 кеше – читтән килүчеләр. Аларның 21е – балалар. Авыручыларның 70 проценты кызамыкка каршы вакцина ясатмаган.

– Вакцинация кирәк. Аны чирләүченең гаилә әгъзалары гына түгел, хезмәт коллективлары да, йорттагы башка кешеләр дә, гомумән, чир теркәлгән урындагы барлык кешеләр дә ясатырга тиеш, – дип искәртте Любовь Авдонина.

Матбугат очрашуында Татарстандагы санитар-эпидемиологик вазгыятькә бәя дә бирелде. Әйтик, грипп һәм ОРВИ сезоны инде тәмам. Чирнең бер-ике очрагы гына теркәлә.

Коронавируска килгәндә, ул әле дә актуальлеген югалтмый. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов әйтүенчә, республикада 14 вакытлыча ачылган йогышлы авырулар госпитале эшли. Шуларда коронавируслы сырхаулар өчен 360 урын бар. 55 кеше стационарда дәвалана, 191 кеше амбулатор дәвалану уза.

Эсселек суны җылытмаган

Татарстанда су коену сезоны ачылып та өлгермәде, инде бәла-казалар да булды. 21–24 майда гына да республика сулыкларында өч баланың гомере өзелде. Иң кечкенәсенә 7 яшь булса, иң олысы – 18ен генә тутырган яшь егет. Бу турыда су коену сезонына багышланган матбугат очрашуында Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе җитәкчесе урынбасары Юрий Венедиктов хәбәр итте. Ел башыннан бирле республика сулыкларында барлыгы 12 кешенең гомере өзелгән, 34 кешене коткарып кала алганнар. Узган елның шушы ук чорында 9 кеше батып үлгән, 20 кеше коткарылган булган. Фаҗигаләр су температурасының җылынып бетмәвенә бәйле.

Быел республика районнарында барлыгы 39 комлык эшләячәк. Моннан тыш, комлыклар 9 ял итү базасында һәм 3 балалар лагеренда да ачылачак.

«Татар-информ»

Яңалык

Июнь ае үзгәрешләре

✓ Автомобильләргә яңа таләпләр куела. 1 июньнән Россиядә барлык машиналар «Евро-2»дән ким булмаган экологик стандартка туры китереп җитештерелергә тиеш. 1 ноябрьдән исә «авто»ны АБС (тормозга басканда, көпчәкнең әйләнмәвен булдырмый) белән тәэмин итү мәҗбүри шартка әйләнәчәк.

Моннан тыш ЮХИДИ хезмәткәрләре җиңел машиналарда «ЭРА ГЛОНАСС» – оператив хезмәтләрне чакыру җайланмасының булу-булмавын тикшерәчәк. Автомобиль мондый җиһаз белән тәэмин ителмәгән очракта, йөртүче аны мөстәкыйль урнаштырырга тиеш булачак. Юкса 50 мең сумга кадәр штраф салу күздә тотылган. Шулай ук быел 1 июньнән 2024 елның 1 февраленә кадәр дустанә илләрдән Россиягә гадиләштерелгән тәртиптә машина кертү тыела.

✓ Тешләрне ГОСТ буенча чистарта башлаячакбыз. Теш щеткасы сыйфатына карата яңа ГОСТ гамәлгә кертелә. Моннан 30 ел чамасы элек эшләнгән ГОСТны алыштырачак ул. Яңа таләпләр, аерым алганда, щетка кылларының туп-туры, тип-тигез булуын, балалар өчен кыл биеклегенең – 8–13, зурлар өчен 9–15 миллиметрдан артмавын күздә тота.

✓ Ана капиталыннан түләүләрне күчерү көне үзгәрә. Өч яшькә кадәрге балага айлык түләү, июньнән башлап, һәр айның бишенче числосында күчереләчәк. Моңа кадәр акча айның егермеләрендә килгән. Акча түләү графигы автомат рәвештә үзгәрә. Ягъни моның өчен Социаль фондка гариза язып тапшыру таләп ителми.

✓ 29 июньнән үзмәшгульләргә товар билгеләрен теркәү мөмкинлеге ачыла. Моңарчы бу хокукка оешмалар яки хосусый эшмәкәрләр генә ия булган. Шулай итеп, хәзер үзмәшгульләр дә шәхси брендларын үстерә алачак. Сүз уңаеннан, Роспатентта 760 меңгә якын товар билгесе бар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

✓ Медицина-социаль экспертизаны, мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, интернет аша гына да узып булачак. Медицина-социаль экспертиза бюросы карарына риза булмыйча, югарыгы оешмаларга шикаять юлларга теләүчеләр экспертизаны шул рәвешле кабат узарга мөмкин.

✓ 1 июньнән шикәр бәясен «йөгәнләп» тору вакыты чыга. Аның бәясе узган елда Министрлар Кабинеты карары белән «катырылды». Күпләп сату бәясе бер килосы өчен – 36 сумнан, ваклап сату бәясе 45 сумнан артмаска тиеш иде.

✓ Җиңел сәнәгать товарларын маркировкалау башлана. Аерым алганда, биредә сүз спорт киеме, пиджак, чалбар, блузка, күлмәк, пәлтә, куртка, ясалма мехтан тегелгән кием-салым турында бара.

✓ Вейплар кибетләрдә генә сатыла башлаячак. Алар белән ярминкә, күргәзмә кебек урыннарда, шулай ук интернет, автомат аша сәүдә итү тыела. Кибетләрдә дә электрон тәмәкене ябык киштәләрдән генә сатачаклар.

Сүзгә-сүз

Татьяна ВАСИЛЬЕВА, Россия мәгариф министры урынбасары:

Бүген яшьләр арасында укытучы һөнәре популяр түгел, дигән фикер нигезсез. Беренчедән, бу һөнәр яшьләр арасында иң популяр булган өчлеккә керә. Икенчедән, педагогика вузларын тәмамлаучыларның 75 проценты мәктәпкә эшкә урнаша. Ягъни дүрт кешенең өчесе педагогиканы сайлый.

(Матбугат очрашуында әйткән сүзләре)

РОССИЯДӘ – КРЕДИТ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге Россиядә яшәүчеләрнең кредит алуда активлыгы турында мәгълүмат тәкъдим итә. Соңгы ун елда бу активлык 1,5 тапкыр арткан.

КЕМНӘР КРЕДИТ АЛА?

25–34 яшьлекләр >>	62%
35–44 яшьлекләр >>	59%
60 яшьтән өлкәнрәкләр >>	46%

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Шифер

Тормыш мизгелләренең беркайчан да диярлек күз алдыннан китми торганнары да була бугай. Кулындагы йөзек кебек алар, һәрвакыт янында, гел үзең белән, барлыгын белеп-тоеп торасың, тик кайвакыт игътибар гына итеп бетермисең. Һәрчак күз алдында булган нәрсәнең кадере беркадәр кими бит ул, беркайчан да югалмас, гел булыр шикелле тоела.

Кайбер күренешләр була да онытыла. Эзсез җуелган сыман. Алар синең тормышыңда бөтенләй булмагандыр сыман. Асылда берни дә җуелмый икән. Ниндидер юк кына сәбәпләр белән теге күренешләр әле кичә генә булган кебек калкып чыга икән.

Әле менә кош-корт сарае төзеп маташам. Түбәсен иске шиферлардан гына ябарга булдым. Ләкин иске иске инде, эшләп бетердем генә дигәндә ярылып та китә. «Ник этләнәм инде шушылар белән, чыгарасы да түгәсе бит», – дип тә уйлап куям. Тик барыбер алай итәргә ашыкмыйм. Төзелеш кирәк-яраклары кыйммәт булган өчен генә түгел бугай. Исраф итү шикелле дә тоела. Һәм искә төшә…

Совет чорының әйбәт яклары да күп булгандыр инде, тик ул дәвердә бөтен нәрсә дефицит иде. Шул исәптән шифер да. Нәрсәдер төзергә җыенасың икән, колхоз председателенә кереп, алдан ук гариза язып чыгасың. Шуннан аны идарә утырышында карыйлар. Расласалар, колхозга кайткан шифер исәбеннән кирәкле данәдә бирәләр. Ләкин бу озакка сузыла. Гаризаңны караганнарын да, раслаганнарын да, шифер кайтканын да, транспорт бушаганын да озак кына көтәргә туры килә. Калай, пыяла ише нәрсәләр белән дә шулайрак иде. Әнинең бик этләнеп йөргәнен хәтерлим. Менә бу шиферлар да – аның әнә шулай айлар буена чират көтеп, интегеп тапкан нәрсәләре. Шуңа аларны чыгарып атасы килми бугай.

Шифер дигәч, моңа кадәр бөтенләй хәтердән җуелган сыман тоелган бер вакыйга искә төшә.

Ферма, МТМ тирәсендә йөргәч, күпне белгәнмендер инде. Олы кешеләр кычкырып әйтергә дә курыккан бер темага (өстәп язу темасына) бер шигырь бар иде. Шуны Башкортстандагы Илеш районының «Маяк» гәзитендә эшләгән шагыйрь Ринат Хәйри бастырып чыгарган. Бу ул чактагы район башлыгы Тәлгать Рахмановка ошамаган. «Кем ул Кәбиров? Нигә шундый нәрсә язып ята? Нука монда алып килегез!» – дип әмер биргән.

Мине абзар артында тирес түгеп яткан җирдән киендереп тә тормый алып киттеләр. Баскычлардан күтәреп дигәндәй алып менеп, тиресле аяклар белән хуҗа алдына бастырып куйдылар.

– Менә Кәбиров.

Рахманов тәрәзәгә карап уйланып тора иде. Шуннан минем якка борылды да катып калды. Аның мәктәп баласын түгел, ә ару гына ир-атны күрәсе килгән иде бугай. Шуннан бу миңа озак кына карап торды да:

– И бала… – дип куйды.

Ни әйтергә белмичәдер инде:

– Нинди шагыйрьне яратасың? – дип сорады.

Мин:

– Әнгам Атнабаевны, – дидем. Һәм өстәп куйдым: – Һади Такташ, Хәсән Туфан, Ринат Хәйри…

– Берәрсенең шигырен беләсеңме?

Мин барсыныкын да яттан белә һәм үземчә бик әйбәт сөйли дә идем. Ул тыңлады. Шуннан йомшак кына итеп баштан сыйпады да:

– Нәрсә телисең, улым? – дип сорады. Кечкенәдән бирле олылар белән аралашып, үземне зур кешегә чутлап йөрсәм дә, ирләрнең «улым» дип әйтүе алдында мин бик кечерәеп кала идем. Монда да күздән яшь атылып чыкты. Тик мин аны тыйдым һәм:

– Морожный, – дидем.

Мин ул вакытта, чынлап та, шуны тели идем. Мин дөньяда «мороженое» дигән нәрсә барлыгын, классташларымның кайсыдыр аны ашаганны һәм аның тәмле икәнен белә идем. Үземнең кабып та караган юк иде.

Шуннан бер ящик «морожный» алып, мине авылга илтеп куйдылар. Безнең холодильник бик бәләкәй иде, шуңа кар базына төшердем. Әни фермадан кайтуга ук, шатланып, барысын да сөйләп бирдем. Мин ул да сөенер, аның да «морожный» ашыйсы киләдер дип уйлаган идем.

Тик аның туңдырмага бик исе китмәде. Сәер караш ташлап, башын чайкап торды да:

– Әй син сантый да инде… Шифер сорарга иде, – дип кистерде.

Менә шул чорларда ук әни юллап тапкан шиферлар инде бу. Сак кына кыланып, әйбәтләп җәеп куйсаң, тагын әллә ничә ел утырырлар әле. Рахманов та юк инде хәзер. Әни дә юк. Шиферлар гына исән. Яшәсеннәр әйдә.

Судка хөрмәт ятты

Рәсми Татарстан

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың Югары Суды Рәисе Илгиз Гыйлаҗевны лаеклы отставкага озатканда шулай диде.

– Республиканың суд системасын үстерүгә керткән бәяләп бетергесез өлешегез өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәсем килә, – диде Рөстәм Миңнеханов, Илгиз Гыйлаҗевка мөрәҗәгать итеп. – Сезнең кебек законга хезмәт итү – осталык һәм эшкә җаваплы карау үрнәге.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Илгиз Гыйлаҗев – эшләү дәверендә абруй казанган шәхес. «Сезнең гадел хөкем нигезләрен белүегез, осталыгыгыз, тәнкыйди фикер йөртү һәм акыл белән исәпләнгән карарлар кабул итү сәләтегез бүген яшь буын юристларны рухландыра. Сезнең катлаулы эшчәнлегегезнең мөһим нәтиҗәсе – суд хакимиятенең абруен күтәрү, халыкның суд системасына ышанычын арттыру», – дип өстәде Рәис.

Илгиз Гыйлаҗев та эшләгән еллары өчен рәхмәтле булуын әйтте. Хезмәт юлыннан истәлекләр белән уртаклашып, җитәкчелеккә рәхмәт белдереп, ул:

– Кем әйтмешли, бергә һәм бары алга! Безнең суд системасының традицияләре дәвамлы булыр дип ышанам, – диде.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе **Гыйлаҗев** Илгиз Идрис улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

СӨЕНСЕННӘР ӘЛЕ!

Яшь укытучыларга – 50 мең сум акча. Яшел Үзән районы җитәкчелеге аларга әнә шундый бүләк әзерләмәкче. Бу хакта район хакимияте башлыгы Михаил Афанасьев Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм Мари Эл Дәүләт Җыенының Социаль үсеш комитетының Яшел Үзән районында узган уртак күчмә утырышында хәбәр итте. Очрашуда укытучы һәм остазларның абруен күтәрү турында сөйләштеләр.

tatarstan.ru

– 2023 елның Россиядә Укытучы һәм остаз елы дип игълан ителүе урынлы. Ул балаларга белем һәм тәрбия бирүне тагын да яхшыртуга җәмгыятьнең, җитәкчелекнең игътибарын җәлеп итәргә булышачак. Укытучылар нәрсәгә мохтаҗ? Аларны ничек әзерләргә? Әлегә укыту эшенең күп өлеше – хатын-кыз җилкәсендә. Укытучыларны борчыган проблемалар турында фикер алышачакбыз. Җитди тәкъдимнәр булганда, ике парламент бер булып, аны федераль дәрәҗәдә күтәрәчәкбез. Әгәр республикада хәл итәрлек булса, үзебез тормышка ашырырга әзер, – диде Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Аның әйтүенчә, әлеге очрашу мәгарифнең торышын, белгечләр әзерләү, укытучыларның матди якларын тагын бер тапкыр тәнкыйди яктан бәяләргә мөмкинлек бирә.

Утырыш башланганчы, Фәрит Мөхәммәтшин, Мари Элның Дәүләт Җыены рәисе Анатолий Смирнов, килгән кунаклар Яшел Үзән шәһәрендә яңа уку елында ачылган 18 нче лицей эшчәнлеге белән танышты. Шунда фикер алышу мәйданчыгында Осиново мәктәбе укытучысы районда яшь укытучыларга ярдәм итү мәсьәләсен кузгатты. Билгеле булганча, аларның хезмәт хакы мактанырлык түгел. Сүз уңаеннан, республикада яшь укытучыларга өч ел дәвамында ай саен өстәмә 2510 сум акча түләнә. Узган ел бу 1 мең сумнан артыграк иде.

– Дөрестән дә, мондый мәсьәлә бар. Без райондагы яшь укытучыларга өч ел дәвамында, елга бер тапкыр 50 мең сум акча түләячәкбез. Моның өчен мөмкинлекләребез дә бар. Әлеге акчаны яшь педагогларга декабрь аенда түләргә җыенабыз, – дип, сөенечле хәбәр җиткерде Михаил Афанасьев.

Уйлады да тәвәккәлләде! Михаил Афанасьевның тимерне кызуында сугуы башкаларга да үрнәк булып тора. Очрашуда мондый ярдәм турында башка районнарга да уйлап карарга тәкъдим иттеләр. 25 мең сум буламы, аннан күбрәкме – ярдәм бит.

Укытучылар арасында биш көнлек укытуга күчү, мәктәпләрне кадрлар белән тәэмин итү өчен, юллама буенча эшкә кайтару кебек тәкъдимнәр җиткерүчеләр дә булды. Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, биш көнлек укытуга күчүнең уңай һәм тискәре якларын аңлатты. «Закон каршы килми. Әмма сәгатьләр саны арткач, укучыларга авырга туры киләчәк. Укытучының да хезмәт хакы кимергә мөмкин», – диде ул.

Мари Элның мәгариф һәм фән министры урынбасары Валентина Гаврилова республикада авыл җирендә эшләүче укытучыларга каралган ташламалар турында сөйләде. Әйтик, анда торак-коммуналь хезмәтләр өчен газга, электрга түләүләр, шулай ук торак арендалап торган өчен акча тулысынча кире кайтарыла икән.

Сәрия МИФТАХОВА

КИҢ МӘЙДАН СИҢА, КАРАВОН!

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Каравон рус халык бәйрәмен уздыру уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне рус халык бәйрәме – Каравон уңаеннан ихлас тәбрик итәм!

Кунакчыллыгы белән дан тоткан Лаеш җирендә бәйрәм тантаналары башлану турында беренче булып Никола храмы кыңгырауларының күңелле чыңлавы хәбәр бирә.

Игенченең зирәклегенә мәдхия, туган җир сулышын тою хисләре белән сугарылган борынгы Каравон хәзер дә үзенә генә хас рухи куәтен саклый һәм элеккечә безне рус традицион мәдәниятенең кабатланмас матурлыгы, җете төсләре белән сөендерүен дәвам итә.

Гүзәл табигатьнең тәэсирен, катнашучыларның йөрәк җылысын һәм җан аваздашлыгын көйле бер агымга берләштергән түгәрәк уен – Никольское авылындагы тантаналарның аерым бер мәгънәгә ия булган символы. Җырлы-биюле әйлән-бәйлән ерак чорлардан буыннан-буынга тапшырыла килгән күркәм гореф-гадәтләребез, тамырларыбыз белән ныклы бәйләнеш хисен тагын да көчәйтә.

Үзенчәлекле рус мәдәниятенең кыйммәтен аңлап, илебезнең төрле төбәкләреннән Каравонга килүчеләр саны арта бара. Бәйрәм мәйданында балаларның шатлыклы гөрләшүе тынмый, ярыш-бәйгеләрдә катнашучыларның кыюлыгы, чаялыгы, яшәү дәрте ташып тора. Яшь буынның уртак тарихи-мәдәни мирасыбыз белән кызыксынуы елдан-ел арту рухи җәүһәрләребезне саклау эшенә һәм күпмилләтле Татарстанның алгарышына бәрәкәтле этәргеч бирә.

2023 елда республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында уздырылган чаралар да моңа ярдәм итәчәк. Бердәм булганда гына без, милли һәм дини аерымлыкларга карамастан, язмышыбыз һәм әхлакый хәзинәләребез уртаклыгын яхшы аңлаган хәлдә, тиңе булмаган тарихи-мәдәни мирасыбызны эчке егәр белән саклап калуга һәм барлык авырлыкларны да җиңеп чыгуга ирешәчәкбез.

Бәйрәмнең оештыручыларына, кунакларына, анда килгән һәркемгә күтәренке кәеф, нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим.

Киң мәйдан сиңа, Каравон!

Тапканчы эзлисе

Берәүгә телефон алып бирмәгәннәр, икенчесе үзенең инде зур икәнлеген исбатларга тели. Хокук сакчылары балалар югалуга китергән иң төп сәбәпләрнең берсе дип шуларны атый. Уку елы тәмамланган чорда ата-аналар баласына карата аеруча игътибарлы булырга тиеш, дип кисәтә алар.

Ел башыннан бирле республиканың хокук сакчыларына балалар югалу турында 224 гариза килеп ирешкән. Россия Эчке эшләр министрлыгы Казан буенча идарәсенең 4 нче «Юдино» полиция бүлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлеге башлыгы – бүлек башлыгы урынбасары Екатерина Папазян сүзләренә караганда, югалучылар арасында малайлар күбрәк. 224 гаризаның 115е аларга кагыла. Югалган балаларның 78е приют, хастаханә, балалар йорты кебек дәүләт оешмаларында тәрбияләнә. Аларның күбесе гариза керүгә үк табыла икән.

– Дүрт баланы исә әле дә эзлибез. 2006 елгы малай үзе тәрбияләнгән оешмадан инде 15 нче тапкыр кача. Хәзерге вакытта без эзләгән өч кызның икесе дә – өеннән даими рәвештә качудан тәм табучылар рәтендә. Югалган тагын бер кыз үсешендә психик тайпылыш булган балалар приютында тәрбияләнә, – ди Папазян.

Яшерен-батырын түгел: беренче карашка мондый гайре табигый хәлләр проблемалы гаиләләрдә генә буладыр кебек. Әмма хокук сакчылары әйтүенчә, югалучылар арасында имин гаиләдә тәрбияләнгән балалар да шактый. Алар, күбрәк әти-әнисе белән сүзгә килгәч, өеннән чыгып китә икән. Араларында юк кына сәбәп аркасында – әти-әнисе телефон яки уенчык алып бирмәгән өчен үпкәләп чыгып китүчеләр дә бар.

Дәүләт оешмаларында тәрбияләнгән бала белән хәлләр мөшкелрәк, ди белгеч. Ник дигәндә, алар инде контрольдән башка яшәп өйрәнгән. Ничек кенә теләсәләр дә, анда эшләүчеләр ятим баланың һәркайсына тиешле игътибарны биреп бетерә алмый. Шуңа аларның күбесе бу оешмадан качып «уйнарга» ярата.

Хокук сакчылары бүген балаларга карата аеруча игътибарлы булырга кирәклеген искәртә. Мәктәпләрдә соңгы кыңгыраулар чыңлаган, БДИ тапшырыр вакыт җитте.

– Бала аттестат алды да зур үсте дигән сүз түгел. Аны элеккечә үк күз уңыннан ычкындырмаска кирәк. Әти-әниләр баласының кемнәр белән дус булуын, аларның телефон номерларын, кая баруларын белеп торырга тиеш, – ди Екатерина Папазян. – Интернет та баланың башын бутый. Анда мошенниклар, нәрсәнедер алып килеп бирүен, ниндидер смслар таратуын сорап, үсмерне кырын эшләргә дә җәлеп итәргә мөмкин. Үсмер бала әле ул яшьтә үзенең гамәлләренә тиешле бәя бирер дәрәҗәдә түгел. Шуңа күрә монда да ата-аналар аң булырга тиеш.

Югалган балаларны табуда эзләү отрядларының да өлеше зур. Бүген республикада шундый алты волонтер оешма эшли. «Лиза Алерт» коткару-эзләү отряды вәкиле Адриана Расписная сүзләренә караганда, әлеге берләшмәләр барысы да хокук сакчылары белән бергә, һәр адымын алар белән килештереп эшли.

– Без урманнарда, шәһәрдә адашкан кешеләрне эзләү белән шөгыльләнәбез. Безгә кешенең кем булуы, нинди вазыйфа биләве мөһим түгел. Без югалган һәркемне тапканчы тырышабыз. Бәхеткә, күп очракта югалучыларны тиз арада табабыз, – ди ул.

Татарстан Эчке эшләр министрлыгы Җинаятьчеләрне эзләү идарәсенең җинаятьчеләрне эзләү эшчәнлеген координацияләү бүлеге җитәкчесе урынбасары Альберт Йосыпов сүзләренә караганда, хокук сакчылары ел саен кеше югалу турында 4 меңләп гариза кабул итә. Быел биш айда гына да шундый 1173 мөрәҗәгать килеп ирешкән инде. «Соңгы арада югалган кешеләр тизрәк табыла башлады. Югалучыларның 95 процентын инде беренче ун көн эчендә табабыз. Моңа кадәр бу сан 89–92 процентны тәшкил итә иде», – дип сөйләде ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КӘЕФНЕ НӘРСӘ КЫРА?

Сөт сатып алу бәясе төшү шәхси хуҗалыкларда сыерларны киметүгә китермәсме? Җитәкчелек бу уңайдан нинди ярдәм тәкъдим итәргә уйлый? Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында шәхси хуҗалыкларга ярдәм һәм башка мәсьәләләр турында сөйләштеләр.

kzn.ru

Төп доклад белән чыгыш ясаган авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ленар Гарипов сүзләренчә, Татарстандагы мөгезле эре терлекләрнең өчтән бер өлеше (261,3 мең баш, шуларның 101 меңе – сыерлар) шәхси хуҗалыкларда асрала. Шунысы кызык: эре хуҗалыкларда сыер саннары кимегәндә, республикада 2005 елдан бирле беренче тапкыр шәхси хуҗалыкларда сыер саны 511 башка арткан. Ләкин менә савып алынган сөт күләме буенча гына мактана алмыйлар. Шәхси хуҗалыклар бер елга бер сыердан уртача 3,5 мең кг сөт савып ала. Чагыштыру өчен, эре хуҗалыкларда бу күрсәткеч 7 мең килограммнан артып китә. Ленар Гарипов хуҗалыкларга азыкны терлек азыгы әзерләү үзәкләреннән алырга киңәш итте. Дөрес сайланган азык ике атна эчендә тәүлеклек савымны 4–5 килога арттыра, диде.

– Эре хуҗалыклардагы һәм шәхси хуҗалыклардагы терлекләрнең продуктивлыгы арасында аерма зур. Без кечкенә чакта, киресенчә, шәхси хуҗалыктагы сыердан 10 литр сөт савып алалар иде. Ул вакытта колхозда 4–5 литр сөт була торган иде, – дип аптырады статистика мәгълүматларына комитет рәисе Азат Хамаев. – Мондый чыгымнар чыгаруның мәгънәсе дә калмый.

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов исә совет заманында мондый югары продуктив терлекләр булмавын, ә колхоз маллары белән чагыштырганда, шәхси хуҗалыкныкыларга игътибар зуррак булуын әйтте.

Ленар Гарипов шәхси хуҗалыкларга күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында да искә төшерде. Аерым алганда, сыер, кәҗә һәм 3 яшькә кадәрге бияләр асраганга, сөтчелек өчен мини-фермалар төзүгә, токымлы бозаулар һәм таналар алуга бирелә торган субсидияләр турында әйтте. Быел кошкорт үстерүчеләрне дә сөендермәкчеләр. Моның өчен бюджеттан 70 млн сум акча бүлеп бирелгән.

Экология комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев игътибарны соңгы елларда фермерларга күрсәтелә торган ярдәм чаралары аз булуга юнәлдерде. Әйтик, 2020 елда аларга 1,4 млрд сум дәүләт ярдәме бирелгән булса, быел нибары 114 млн сум гына.

– Мондагы программаларның күпчелеге федераль казнадан финанслануны аңлыйм, ләкин мондый караш булганда, федераль үзәктән ярдәм турында сөйләргә туры килми, – диде ул.

Аңа каршы Ленар Гарипов Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының төрле программаларның суммасын үзгәртеп торуын әйтте. Кайвакыт теге яки бу грантка дәгъва кылучылар саны кимеп киткән очракта, республика министрлыгы да бер программага билгеләнгән акчаны икенчесенә күчерүне сорый.

Ярдәм чаралары булып торса да, комитет утырышында катнашучылар ел башыннан сөт сатып алу бәяләренең төшүен дә игътибарсыз калдыра алмады.

– Сөткә бәя төшкәннән соң, халыкның кәефен сораштыгызмы яки Росстат тикшерүләре уздырылдымы? Баш саннары сакланамы әле, түбән тәгәрәмәдеме? – дип мөрәҗәгать итте Марат Әхмәтов Ленар Гариповка.

Аңа җавап итеп, министр урынбасары: «Баш саннары саклана, ләкин кешеләрнең кәефләре… начар», – диде.

– Бу тенденция бөтен республика буенча күзәтелә. Баш саннарын саклап калсыннар өчен, районнар, авыл хуҗалыгы идарәләре, авыл советлары белән сөйләшәбез. Мондый хәл беренче генә тапкыр түгел инде. 2006, 2010 һәм 2018 елларда шулай булган иде. Базардагы вазгыять көзгә тотрыкланырга тиеш. Һәрхәлдә, Россиядәге сөт эшкәртүче зур заводлар шулай дип вәгъдә бирә. Терлекләрне саклап калырга өметләнәбез, – диде Ленар Гарипов.

Вазгыятьне искә алып, министрлык, авыл хуҗалыгы оешмаларына сөт сату чыгымнарын каплар өчен субсидия сорап, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать иткән иде. Нәтиҗәдә республика бюджетыннан 523 млн сум акча бүлеп биреләчәк. Субсидияләрне мартта һәм апрельдә сатылган сөт өчен алырлар дип ниятлиләр. Ленар Гарипов әйтүенчә, акчаны июньдә бирергә планлаштыралар.

Ярдәм – саннарда

▶ Биш һәм аннан күбрәк сыер асраучыларга мини-ферма төзер өчен – **300** мең сум, сигез һәм аннан күбрәк сыер асраучыларга **600** мең сумга кадәр акча бирелә. Шартлары: программада катнашучылар мини-ферманы ярты ел эчендә төзеп бетерергә, аннан соңгы елда сыер санын арттырырга һәм аны биш ел сакларга тиеш.

▶ Токымлы бозаулар һәм таналар сатып алган очракта, **60** һәм **70** мең сум күләмендә ярдәм чарасы каралган.

▶ Бер сыер асраучыларга – **2** мең, ике сыерга – **3** мең, өч һәм аннан күбрәк сыерга **4** мең сум акча бирелә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

Рәхәт кеше

Кайчан гына очрашсаң да, кояш кебек яктырып, гел үзенә тартып торган кешеләр була. Гомер бакый шәһәребездә сәүдә хезмәтендә һәм аның да совет заманнарындагы авыр товар-йөкләрен үз җилкәсендә күтәрептаашып, транспорт якларына тикле тулаем оештыруны армый-талмый башкарып, бәхетле картлыгын да шулай зарынтизар итмичә матур үткәрүче Әдилә апа белән күрешсәң, күңелләр ачылып-яктырып китә. Ул – ихлас, үтә ачык, йөзендә кояш балкышы. Менә нинди рәхәт кеше, дип куясың.

Ничек сокланмыйсың инде, 72 яшендә ул япа-ялгызы нинди җитешле йорт төзеп кергән. Бүген Әдилә апага 82 тулган, баскан җирендә ут чыгара әле! Үзе яшәгән шәһәр яны бистәсен төзек-үрнәк тотуда нәрсәдер килеп чыкканда, тикмәгә генә аңа әйтмиләрдер. Үзе кебек өлкәннәргә һәрчак ярдәмләшергә әзер ул. Мәсьәләне уңай хәл итәр өчен югары даирәләргә кадәр барып җитәр һәм тиешле ноктаны куймыйча туктамас. Бу четерекле заманда әле дә Әдилә апа кебек сабыр-булдыклы, тынмас йөрәкле ватанпәрвәрләребез бар. Шундый рәхәт кешеләре белән Азнакаем матур минем, олы, эшчән, ягымлы-кунакчыл да.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җәйге яңгыр

Болыт чабуларын җилфердәтеп,
Күкри-күкри җәйге яңгыр узды.
Җәйге яңгыр хәтерләтә миңа
Уңган агрономны – абыемны...

Ул кояшлы җәйге яңгыр иде,
Күкрәүләре, яшеннәре булды.
Коеп яуды, оеп яуды да ул
Китеп барды... Калды шифа-моңы.

Дымга тиенеп калды басу-кырлар,
Аның төсе булып калды Икмәк.
Кояш төсле Икмәк үлемсез ул, –
Аны үстергәннәр Җирдән китмәс!

Шулай күкри-күкри, еракларга
Китеп барды. Ул кат-кат кайтыр әле
Сагындырган җәйге яңгыр булып...

Шамил МАННАПОВ

Синсез килгән язлар...

Көтмәгәндә генә газиз балаңны югалтудан да ачы хәсрәт юк икән. Кадерле улыбыз, гвардия лейтенанты Айнур Измайлов та Украинада махсус хәрби операция вакытында һәлак булды. Аңа нибары 24 кенә яшь иде.

Вафатына бер ел вакыт узса да, үлеменә күңелебез һаман ышанмый... Үзе исән чагында да улыбызның дуслары, танышлары гаять күп иде. Аны барысы да үз иттеләр, яраттылар. Үлеме белән бик күпләр килешмәде, хәзер дә ул барыбыз өчен дә исәндер шикелле...

Улыбыз Кукмараның 3 нче урта мәктәбендә белем алды. Аны монда онытмыйлар. 2022 елның 8 маенда Җиңү көне уңаеннан үткәрелгән тантаналы линейкада да искә алдылар. 8 нче сыйныф укучылары җитәкчеләре белән берлектә каберенә чәчәкләр куйдылар. 1 сентябрьдә истәлек тактасы урнаштыруга багышланган тантаналы митинг оештырылды. Бу эш, Ватанга тугрылыклы булып, илебез иминлеген саклауда үзләрен аямыйча, яу кырыннан кайтмый калган батырларның исемнәрен мәңгеләштерү йөзеннән башкарылды. Мәктәп директоры Диләрә Ганиева инициативасы белән Айнур истәлегенә музей почмагы да булдырдылар. 23 март көнне аны рәсми төстә ачу тантанасына безнең гаиләне дә чакырдылар.

Мәктәпнең ишеген ачып керүгә, улыбызның фотосы эленеп тора. Ул бар кешене сәламли кебек. Музей почмагында исә шәхси әйберләре – киемнәре, орден, медальләре, грамоталары урын алган. Монда куелган һәр әйбер бик күп нәрсә турында сөйли. Улыбызны хөрмәт итүләренә бик сөендек. Хәтер кичәсенең икенче өлеше халык белән шыгрым тулы актлар залында узды. Мәктәп коллективының, укучыларның бик күп көч куюлары әллә каян күренеп торды. Мәктәп директоры Диләрә Хәкимовна: «Безнең мәктәптә Айнур шикелле кыю йөрәкле егетләрнең белем алуы – горурлык, әмма аларның безне иртә ташлап китүләре белән һич кенә дә килешәсе килми. Аның кылган батырлыгын онытмыйча, музей почмагын киләчәктә тагын да тулыландырып, укучыларга аның турында һәрчак искәртеп торырбыз», – диде. Кукмара районы хәрби комиссары Альберт Гомәровның, олы улыбыз, майор, батальон командиры Ленар Измайловның, Кукмара районы ветераннарының «Сугышчан туганлык» иҗтимагый оешмасы әгъзаларының сөйләгәннәрен бөтен зал тын алмыйча тыңлады. Музейны оештыруга зур өлеш керткән тарих укытучысы Марина Евгеньевна, Айнурның сыйныф җитәкчесе булган, бүген тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләүче Ләйсән Фердинантовна, улыбызны белгән һәр кеше аның тарафына бары тик җылы сүзләрен җиткерде. Кичәдә яңгыраган үтемле сүзләр, мәгънәле җырлар, шигырьләр – барысы да улыбыз рухына дога булып барып ирешсә иде...

Айнур истәлегенә районның «Барс Арена», «Зилант», «Ялкын» спорт сарайларында ярышлар үткәрелеп килә. 15 апрельдә мини футбол буенча I ачык турнир ныклы әзерлек белән узды.

Улыбыз кечкенәдән үк спортны үз итте. Хәрби училищеда укыган елларында Айнур Казан шәһәренең «Кадар» спорт сараенда самбо белән шөгыльләнде. Анда да аның истәлегенә даими ярышлар үткәрелеп тора.

Күптән түгел Айнурның абыйлары ул хезмәт иткән җирдә булып кайтты. Алар сөйләве буенча, Улан-Удэ шәһәрендә урнашкан частьта махсус хәрби операциядә һәлак булган солдат, офицерлар истәлегенә хәтер почмагы булдырылган.

Олы кайгыбызны үзләренеке итеп тойган, җылы сүзләре белән юаткан, матди һәм рухи ярдәм иткән һәр кешегә чиксез рәхмәтебезне җиткерәбез. Безнең башка төшкән ачы хәсрәт һәркемне читләтеп үтсен иде. Сугышлар тынып, илләребез имин булып, барчабызга исән-сау яшәргә язсын.

Раушания ИЗМАЙЛОВА.
Кукмара

ТАБЫЛДЫКЛАР УРЫНЫ

Урта Идел төбәге геологик һәм табигый шартларга бай. Шул ук вакытта бик күп табылдыклар урыны да әле ул. Мин Казанга хатыным, танылган опера җырчысы Рәисә Нуриева белән Үзбәкстаннан күченеп кайттым һәм Татарстан геологиясенә зур өлеш керттем дип саныйм. Геология – минем булмышым, шуңа кайбер тәкъдимнәр белән бүлешергә булдым.

Төрле хезмәтләр һәм ведомстволар геологлары казна акчасына Россия халык хуҗалыгы өчен файдалы казылмалар эзләгән бер мәлдә, бүгенге катлаулы шартларда кайбер фидакарьләр дә фәнгә, җитештерүгә ярдәм итү максатыннан мөмкинлекләр эзләп табарга тырыша. Әйтик, «Фома XXI» үзешчәннәр төркеменә керүчеләр – шундыйлардан. Без Идел, Кама, Зөя, Терешка, Чусовой, Казансу, Нокса елгалары ярлары буенда, табигатькә зыян салмыйча, ягъни чүкечкәйлә һәм көрәк кулланмыйча гына, эзләнү-тикшеренүләрнең тулы бер системасын җайга салдык.

Кызганычка, кайберәүләр атаклы Лобач тавы итәгендә зур егәрлекле чүкечләре белән барлык чакма ташларны һич кызганмыйча ватып китә. Алар табигатькә карата шундый вәхшилек күрсәтү белән беррәттән, үзләреннән кешеләрнең аякларын яралау, җил белән күзләренә керү куркынычы тудырган вак ташлар өеме дә калдыра.

Безнең төркем яр буйларында очрый торган искиткеч матур сары төстәге, сталактик һәм сталагмитларга охшаш арагонит ташына бигрәк тә мөкиббән. Аны, яратып, «нуриевит» («нур» сүзеннән) дип атыйбыз. Елга тугайларында, бигрәк тә көнбатыш юнәлештәге тау битләрендә еш очрый ул. Пермьның селениты яки Балтыйк буеның гәрәбәсе кебек, Идел буе төбәге өчен хас таш бу. Дизайнерлар, ювелирлар халыкка нуриевитның матурлыгын, дәвалау үзенчәлекләрен төрле юллар белән аңлатырга тырыша. Ләкин таш кисәкләре, юка пластиналар әлегә музей киштәләре һәм коллекционерларның җыелмаларын гына бизи.

Әмма гади халык өчен бу ташларны күрү, тотып карау хыялдан чынбарлыкка әйләнергә мөмкин һәм тиеш тә. Алар Идел буе төбәгенең җир асты байлыкларын тәшкил итә чөнки. Язгы ташу һәр ел саен җир өстенә бу ташларны чыгарып тора. Шушы чорда игътибарлы һәм кызыксынучан гына булырга кирәк. Табылдык таш исә фән, музейлар өчен, ә иң мөһиме – мәгариф өлкәсе: мәктәпләр, көллиятләр, институтлар һәм университетлар өчен мөһим.

2022 елда фән һәм технологияләр унъеллыгы башланды. Фәнни волонтерлык – унъеллыкның башлангычларыннан берсе. Һәркайсыбыз нәрсәдер табып, фәнебезгә ярдәм итәргә мөмкин. Дәүләт бюджетына яшәүче зур фәнгә, әлбәттә, волонтерлык ярдәме кирәк. Волонтерлар эзләп тапкан материаллар белән фәнни, шәхси яки мәктәп коллекциясен тулыландырырга мөмкин.

Күпьеллык эш тәҗрибәсеннән чыгып, шуны әйтергә мөмкин: зур табылдыкларны, фотога төшергәннән соң, шул урында (ниндидер билге урнаштырып) калдырырга кирәк. Өйгә (мәктәпкә һ.б.) алып кайтылган табылдыкларны саклау күп кенә проблемалар китереп чыгара. Казан федераль университетының геология музеенда (элекке дини семинария бинасы), Татарстан табигать тарихы музеенда (Казан Кремле территориясендә юнкерлар училищесы корпусы) урын аз, һәм аларга кереп булмый диярлек. Шуңа күрә якын киләчәктә җыелган материалны туплап, саклау өчен терминаллар төзергә кирәктер. Әйтик, Казандагы Магистральная урамының көньяк очында, Дальний бистәсендә ВНИИгеолнеруд институты базасында.

Тикшеренүчеләргә ярдәм итүче волонтерлар маршрутларының күпчелеге, кагыйдә буларак, зур һәм кечкенә елгалар буйлап уза. Бу исә туып-үскән төбәк белән тагын да якыннанрак танышу мөмкинлеге бирә. Табылдыклар эзләү өчен иң уңайлы вакыт – апрель уртасына кадәрге чор һәм октябрь ае. Җәен су күтәрелгәнлектән, май аенда яшеллек пәйда булганлыктан, эзләү эшләре алып бару кыен.

Родион СУББОТИН.
Казан

Биш елда – мең дә бер яңалык

Чүпрәле муниципаль районы башлыгы Марат Гафаровның безнең районга эшкә килүенә биш ел булды. Бу әле үтә дә җаваплы хезмәтнең беренче этабы гына дип уйларга кирәк.

Шушы биш ел эчендә район җирлегендә бик күп социаль объектлар сафка басты, капиталь төзекләндерү үткәрелде. Алар арасында дистәдән артык мәгариф учреждениесе, күпфункцияле өч үзәк, «Созидание» яшүсмерләр клубы, алты фельдшер-акушерлык пункты, дүрт спорт объекты һәм алты универсаль спорт мәйданчыгы бар. «Безнең ишегалды» республика программасы буенча күпфатирлы йортларның дүрт ишегалды территориясе һәм өч торак пункт төзекләндерелде. Районның биш авылында комплекслы хезмәт күрсәтү пунктлары ачылды. Халыкны эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү максатыннан 2018–2022 еллар дәвамында 229 чакрымга якын сууткәргеч яңа торбалар салынды. Шулай итеп, 41 авылга сыйфатлы су килде. Иске Чүпрәле авылында Абдулхак Алимов чишмәсе тергезелде. Гомумән, безнең районда чишмәләргә, аларны төзекләндерүгә соңгы елларда игътибар нык артты. Хәзерге вакытта район халкының 78 проценты чишмә суы эчә. Кыш айларында социаль-мәдәни объектларда тиешле җылылык тоту өчен, зур егәрлекле алты казан урнаштырылды. Юкка гына юлларны «тормыш артериясе» дип атамыйлар. Шушы биш ел эчендә төбәк, муниципаль һәм җирле әһәмияттәге юллар төзелде һәм төзекләндерелде. Монда әле санап кителмәгән эшләр дә бик күп. Боларның барысы өчен программалар нигезендә республика һәм федераль бюджеттан 4,5 миллиард сум акча тотылды.

Бар көчен, тәҗрибәсен һәм һөнәри осталыгын туплап, Чүпрәле районы халкының яшәү рәвешен яхшырту максатында намус белән шулай эшләве өчен без Марат Ринатовичны ихлас күңелдән хөрмәт итәбез. Ул беренче көннән үк үзен таләпчән, хезмәт сөючән, булдыклы җитәкче итеп танытты. Хезмәтен һәрчак күңел җылысын салып башкара. Нәтиҗәләр артында гаять зур хезмәт, эшкә заманча якын килү, принципиальлек, зур оештыру сәләте һәм үзенә генә хас булган эшлеклелек, кешелеклелек сыйфатлары ята. Район халкы аңа таяна, берсеннән-берсе матур эшләренә соклана.

Күптән түгел җитәкчебез туган көнен дә бәйрәм итте. Ихластан тәбрик итәбез, корычтай нык сәламәтлек, гаилә иминлеге телибез.

Абдулхарис АЛИМОВ.
Чүпрәле

Очраклы кеше кыйссасы

Очраклы гына туганмын. Күпбалалы гаиләбездә миңа кадәр барлык малайлар йә үле килеш дөньяга килгән, йә туганнан соң берничә көн яшәгәч үк гүр иясе булган. Әнием ягыннан бик дини әбиемнең зирәклеге белән генә исән калганмындыр дип уйлыйм: миңа ул, озын гомерле булсын дип, Коръәндәге Локман исемен кушкан. Ни гаҗәп: миннән соң сау-сәламәт малайлар туа башлаган.

Укытучы булып китүем дә очраклы гына килеп чыкты. Безнең Мамадыш районында, педучилищедан тыш, башка бер генә махсус уку йорты да юк иде. Җиденче сыйныфтан соң шунда кереп уку үтә зур белем алуга саналды. Ул вакытта хәтта бик зур колхозыбыз рәисе дә надан иде: белешмәләргә имза урынына аркылы-торкылы таяк кына куйды.

Офицерга әйләнүем дә очраклы гына. Яшерен-батырын түгел: «крепостной» колхозда бер караңгыдан икенчесенә кадәр, алсыз-ялсыз таякка эшлисем килмәде. Колхозчыларның паспортлары юк. Ял көнне базарга барып кайту өчен бригадирдан, кайвакыт хәтта колхоз рәисеннән сорап китәсе. Атна буе үргән чабаталарымны сату өчен, әнием белән җәяүләп, сигез чакрымдагы район үзәге базарына еш йөрдек. Шушы җәһәннәмнән качып китү һәрбер малай-кызның алсу хыялына әйләнде. Кызлар – шәһәр егетләренә кияүгә чыгып, ә егетләр исә хәрби хезмәттән соң армиядә калып, хыялын тормышка ашырырга тырышты. Урта белемле солдат буларак, мине хәрби авиаучилищега укырга җибәрделәр. Аны тәмамлаганнан соң Совет армиясендә офицер булып хезмәт иттем. Таякка түгел, ә акчага эшләдем.

Язучы булып китүем исә хәтта хыялда да юк иде. Мин үскәндә, колхозчы баласы китап актарып утырмады. Инде 8 яшьтән үк, кайберләре алданрак та, әти-әнисенә йорт эшләрендә ярдәм итәргә тырышып үсте. Барысы да җиң сызганып эшләп йөргәндә, ничек инде китап укып утырасың ди?! Мәктәбебездә Горькийның «Мои университеты» геройларына охшарга теләүчеләрнең балалар колониясенә эләгүен кызганып искә алам.

Пенсиягә чыккач, Горбачевның үзгәртеп кору елларында үз фикереңне курыкмыйча әйтеп салу мөмкинлеге ачылгач кына, мәкалә, очерк һәм хикәяләр яза башладым. Ул чагында хөр фикер йөртүчеләр аз иде. Язмаларым «Литературная газета»да, «Огонек» һәм бик күп тиражлар белән басылучы башка үзәк басмаларда дөнья күрде. Алар шундук «Голос Америки», «Би-би-си», «Азатлык» радиолары аша да тапшырылды әле. Үземә ир-ат халаты тегәргә маташкан өчен аздан гына психушкага эләкмичә калуымны тасвирлаган «Жил в стране советской несоветский человек» дигән язмам укучылар күңеленә бигрәк тә хуш килде. Аның өчен үземә доллар белән шәп кенә гонорар алу бәхете елмайды. Советлар чорында ир-атлар буржуйларның велюр халатын түгел, ә буй-буй пижама киеп йөрергә тиеш иде...

95 яшьлек юбилеем быел февраль аенда Тукай клубында Татарстан Язучылар берлегендә әдәби-сәнгать кичәсе рәвешендә шаулап-гөрләп узды. Анда танылган артистлар борынгы татар җырларын үзәккә үткәзеп башкарды.

Әлеге матур кичәне оештырган, түшемә Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премия медален таккан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ркаил Зәйдуллага, кичәнең режиссеры, драматург Хәбир Ибраһимов, клуб директоры, җырчы һәм баянда уйнаучы Рафаил Сафин, Татарстанның халык артисты Азат Хөсәеновка, татар җырларын искиткеч матур башкаручылар – Наилә Яхина, Фәрзәнә Кулиевага (әле кайчан гына КАИда математика укытучысы булып эшләгән!) һәм башкаларга чиксез рәхмәтлемен.

Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары, халык язучылары һәм шагыйрьләр Рабит Батулла, Равил Фәйзуллин, Газинур Моратның чын йөрәктән әйтелгән җылы сүзләре күңелемә сары май булып ятты. Аларга да бик зур рәхмәт!

Сүз уңаеннан, юбилеемның тарихи вакыйгага әйләнүен дә әйтеп үтәргә кирәктер. Язучылар берлеге тарихында 95 яшьлек язучыны хөрмәтләү кичәсе булмаган әле. Минеке – беренчесе...

Локман ЗАКИРОВ

КҮҢЕЛЛӘР ЕРАГАЙМАСЫН

Гаиләгә кагылышлы бәйрәмнәр болай да бик күркәм, быел исә, Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы булгангамы, аеруча зур әзерлек белән үтә алар. Чөнки һәр гаилә – үзе бер дәүләт. Анда, сәяси дәүләттән аермалы буларак, язылмаган һәм, аларны үтәмәсәң, җавапка да тартмый торган кануннар идарә итә. Гаиләнең нигезе – бер-береңне ярату, хөрмәт итү һәм үзеңдә җаваплылык тою. Гаилә кору ул инде – үзең өчен генә яшәмичә, башкалар язмышын да кайгыртып яши башлау. Гаиләнең үткән юлы – юл кагыйдәләре күрсәтелгән асфальт юл түгел.

Әнә шуларны истә тоткангадыр, гомер юлын парлап кичкән, алтын, зөбәрҗәт, бриллиант туйларын күрү бәхетенә ирешкән парлар байтак. Районыбыздагы шундый 12 парны күптән түгел Актанышның ЗАГС бүлегенә кунакка чакырдылар. Залга керү юлында ук һәр кешене бәйрәм рухы белән каршы алдылар, зур хөрмәт белән, билгеләнгән урыннарыбызга озатып куйдылар. Алтындай вакытын кызганмаган, һәр парга җылы сүзен таптап кан, чәчәк бәйләмнәре һәм бүләкләр тапшырган район хакимияте башлыгы Ленар Рафак улы Зарипов һәрберебезгә ихлас теләкләрен җиткерде. Парларны ак кәнәфигә утыртканнан соң, ЗАГС бүлеге җитәкчесе Гөлфинә Баян кызы аларның тормыш юллары белән таныштырды. Һәр гаиләнең дәвамчылары – балалары, оныклары котлавы нур өстенә нур өстәде. Кичәдә башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дилбәр Әнвәр кызы да катнашты.

Бәйрәм «Туган җиремә» җырына кушылып вальс әйләнү белән тәмамланды. 70–80 яшьлек кешеләрнең, бәлки, күптән биегәннәре дә булмагандыр – анысы үзе бер күңелле тамаша булды.

Һәр чара оештыручыларның мөнәсәбәтеннән тора: бу кичә үзенең бик әзерлекле, мәгънәле, эчтәлекле булуы белән күңелдә сакланыр, яшь буынга гаилә кыйммәтләре турында уйланырга этәргеч булыр. Егет белән кыз йөргән чагында күбрәк пышылдашып сөйләшәләр, чөнки аларның күңелләре якын була. Менә ир белән хатын булгач, кайчак кычкырыша башлыйлар, бер-берсен ишетмиләр – күңелләрнең шулай ерагаюымы әллә бу?.. «Акыл – алдан, ачу арттан йөри» – күңелләр ерагаймасын, аерылышулар булмасын, балалар ятим калмасын өчен, гомер көзендә алтын, зөбәрҗәт туйларны каршылар өчен, татар халкының шул мәкален истә тотып яшәү кирәктер.

Зәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА.
Актаныш районы Качкын авылы

Ватан хакына

АЛСУ СӘЙФУЛЛИНА:

«Улым белән горурланам»

Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләр, чиратлашып, туган якларына ике атналык ялга кайта. Саба районының Йосыф Алан авылы егете Инсаф та гаиләсе янына кайтты. Сигез ай буе көткән очрашу иде бу. Хатыны, ике баласы, әти-әнисе, туганнары Инсафны зарыгып көткән.

– Ирем белән өч бала үстерәбез. Инсафым – иң олысы. Мин аны 20 яшемдә таптым. Аннан соң кызым туды, мәктәптә укучы кечкенә улыбыз бар. Инсафыбыз иртә өйләнде, 19 яшендә гаилә корды. Киленебез – күрше авыл кызы. Бер-берсенең беренче мәхәббәтләре алар, – дип сөйли Инсафның әнисе Алсу. – Яшь булсалар да, бала хәсрәте дә күтәрделәр. Беренче сабыйлары туып, ике генә көн яшәде дә вафат булды. Бик авыр хәл, үз хәлләрен үзләре генә белгәндер. Озак та үтми, икенче бәби көтүләрен белдек. Ул сабый җитлекмичә туды. Аннан соң тагын бер бәби алып кайттылар. Дөресрәге, әтисе мобилизацияләнеп, «Казан Экспо»да өйрәнүләр үткәндә туды ул сабый. Улым, ике генә сәгатькә кайтып, баланы каршы алды.

Инсаф элек хәрби хезмәтен Чита шәһәрендә узган була. Әнә шул чакта Ватанга мәхәббәте уяна да инде аның. Чын ир булып кайта ул аннан. Махсус операциягә чакыру килгәч тә, икеләнеп тормый, барам, дип әйтә. Авыру баласы, үзе крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе булса да, чакыргач, юлга кузгала, калу юлларын эзләми. Дөрес, ире киткәч, хатынына ике сабый белән җиңел булмый. Баштарак әнисе белән әбисе ярдәмләшә.

– Илгә килгән кайгы бит. Бер безгә генә килмәде. Шуңа да сабыр итәм. Улым кебек күпме егетләр Ватанны яклый. Әниләре – догада, сөйгәннәре теләктә тора. Безгә җибәрелгән бер сынау инде бу. Берни эшләп тә булмый, балаларыбызга шундый чор эләкте. Димәк, язмышларына язылган булган. Солдатларның гаиләләренә дәүләт төрлечә ярдәм итә. Елап утырып, эш чыкмый, нишлисең, – ди Алсу. – Ирем дә, Инсаф улым да көчле характерлы. Алар бер әйтә дә башка кабатламый. Ярган юлларыннан бара торган кешеләр. Үз сүзләреннән кире кайтарып булмый. Мин моның белән горурланам да. Чүпрәк егет үстермәгәнбез, дим. Безне, илне, гаиләсен кемдер сакларга тиеш бит инде.

Алсуга рас килә торган төшләр дә керә икән. Улын махсус хәрби операциягә чакырганчы ук, ул илдә нидер буласын төшендә күргән. Улының китәсен дә алдан белгән.

– Чакырулары да тиз булды. Нәрсә алырга икәнен дә белмибез. Улым тиз-тиз җыенып чыгып китте. «Казан Экспо» да вакытта янына барып йөрдек. Мин аны әллә кая еракка китәр дип уйламадым да. Хәрби өйрәнүләр узар да кайтыр дип көткән идек. Әмма без уйлаганча булмады. Балам китеп барды. Әнә шулчакта бер яктан еласам, икенче яктан улымның көчле рухына сокландым. Ир бала гомер буе хезмәт иткән бит инде ул. Бабайлар да сугышта булып, илне яклаган. Сабырлык кирәк, – ди Алсу.

Әнисе Инсафның ялга кайтасын белсә дә, улы өйгә килеп кергәч каушап та киткән. Иң татлы очрашу булган ул. Улы гаиләсе белән туган йортка кайтып кергән чакны Алсу бик кадерләп сөйли.

– Улымны бик сагынган идем! Үзең ашасаң да, йомшак урынга ятып йокласаң да, балаң уйдан чыкмый бит инде ул. Малай үстерүче әниләр мине аңлар. Шуңа да ана бит без. Төн йокыларын калдырып башта бактык, хәзер исә исәнлеген теләп торабыз. Улым үзгәргән. Элеккеге яшь егет түгел инде. Дөнья күргән ирләр рәвеше кергән. Күп сөйләшми, андагы хәлләрне әйтми. Безне борчымаска тырыша. Әмма янәшәсендә бер телем икмәкне икегә бүлгән, бер савыттан ашаган, бер чокырдан су эчкән егетләре хакында яратып сөйли. Чын егетләр дуслыгының ни икәнен белгән ул, – ди Алсу. – Баламны күрүгә, ирексездән елап җибәрдем. Зур гөлләмәләр күтәреп кайткан. Исен дә сагынган идем улымның.

Инсафның элемтәгә чыкмаган чаклары да күп икән. Андый вакытта Алсу Коръән укый. Бары тик догалар гына тынычландырып тора икән.

– Диндә булу коткара. Бар әниләргә дә дога укырга киңәш бирер идем мин. Ана догасы пәрдәләрсез кабул булыр, диләр бит. Шуны онытмыйк. Улым үзе дә мин өйрәткән догалар белән йөри. Без Инсафның исән-имин яныбызга кайтуын теләп торабыз. Әле аның тормышының иң матур чагы. Хатыны белән тигезлектә сабыйларын аякка бастырасы бар, – ди әнисе. – Янәшәбездә генә толлар да, ятимнәр дә бар, нишлисең… Авыр хәсрәт килгәннәргә сабырлык телим. Һәр ананың баласы үз якларында кайтса иде. Алда сөенеп яшәр көннәр күп булсын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сәяхәт

Казан шәһәрендәге Бишбалта бистәсе – татарлар яшәгән иң тарихи урыннарның берсе. Әмма, ни кызганыч, күп вакыйгалар инде гасырлар төпкеленә төшеп югалган диярлек. Гомеренең күп өлешен шушы бистәдә эшләп, бүген дә шунда яшәүче Гарәфетдин Хисаметдинов, шул хатирәләрне барлап, Бишбалта тарихын язарга алынды. Тирәнрәк өйрәнгән саен, тагын да кызыклырак хәлләргә юлыга Гарәфетдин абый. Бишбалта татарларының тормышында без белмәгән якларны ача, башында яңадан-яңа идеяләр туа. «Көмеш дага» дип аталган сәяхәт маршруты да – шундыйларның берсе.

Илдар Мөхәммәтҗанов

КӨМЕШ ДАГА

:: Гарәфетдин абый, тарих битләреннән күренгәнчә, Бишбалта ялгызы гына булмаган, аның тирә-юнендә татар тормышы кайнаган...

– Белгәнебезчә, Бишбалта бистәсе Арсу елгасы (Казансу елгасы тарих китапларында шулай дип исемләнгән) Итилгә (Идел елгасының борынгы исеме) кушылган җирдә барлыкка килгән. Су буенда урнашкач, аңлашыла ки, монда яшәүчеләрнең каеклары да, көймәләре дә, саллары да, башка йөзү җайланмалары да булгандыр. Каршыдагы Ослан тавы, мул сулы Итил елгасын кискен генә көньякка, Хазар (Каспий) диңгезенә таба борып җибәрә. Бишбалта авылыннан ерак түгел, каршыда гына Мәркиз утравы урнашкан. Язгы ташу вакытларында су астында калып, ташулар беткәч, утрауны яшел хәтфәдәй печән басып китә. Бу хакта бик күп язучыларның әсәрләрендә дә искә алына. Мәркиз – яшьләрнең яраткан ял итү урыны була, шулай ук Ефәк юлы буйлап килүче сәүдәгәрләрнең сәүдә итү һәм ял итү үзәге дә булып тора. Сөзәк елга ярлары, язын-җәен ташулар киткәч, мул печәнле аланнарга, ягъни малларны ашатыр өчен менә дигән урыннарга әйләнә. Кышлыкка мул итеп печән чабучылар, ашлык уручылар шушы тирәдә туплана. Алар үзләренең торган урыннарын Уракчы (Аракчино) авылы дип атыйлар. Тора-бара башка авыллар да барлыкка килә. Менә аларның исемнәре – Яңа Уракчы (Новое Аракчино), Кызыл Яр (Красная Горка), Хуҗа Әхмәт (Куземетьево). Владимир Ленин күрсәтмәсе буенча Кызыл Яр авылының исеме 1918 елда Казанны ак чехлардан азат иткәндә һәлак булган комбриг – латыш укчысы Ян Юдин хөрмәтенә Юдино дип үзгәртелә. Кызганыч, бу авылларның татарча исемнәре хәзерге көндә кулланылышта юк. Югыйсә шундый матур яңгырый торган исемнәр бит.

:: Әле без белгәндә дә башкаланың Елга порты Бишбалтада урнашкан иде. Дөресрәге, анда шундый корылма барлыгын белгерткән калдыклар бар иде. Мондый пристаньның янәшәдә булуы татар авылларына тормыш итү өчен бик уңайлы булгандыр?

– Чыннан да, ике елга кушылган җирдән ерак түгел йокым (элек пристаньны шулай дип атаганнар) барлыкка килә. Аны «Бакалда йокымы» дип атыйлар. «Ни өчен мондый сәер исем биргәннәр?» дигән сорау туарга мөмкин. Җавабы бик гади: анда сулар, күлләр бик чиста, балыклар, бакалар күп булган. Белгәнебезчә, бакалар бик чиста. Элеккеге заманнарда суыткычлар булмаган, сөт әчемәсен дип, сөткә хәтта бака сала торган булганнар. Бишбалта халкы шуңа күрә дә бакаларны үз иткән, аларны куркытмаган. Ә бакалар җавап йөзеннән бакылдарга яратканнар, бик тиз үрчегәннәр. Шулай итеп йокымга Бакалда дип исем кушылган. Яңа елга порты төзелгәнче, 1957 елга кадәр Казан шәһәрендә Бакалда йокымын кулланганнар әле. Ул 1,5–2 чакрымга сузылган була. Шәһәр белән элемтә булсын өчен, таш түшәлгән Ташаяк юлы салына. Ул хәзерге Таҗи Гыйззәт урамы белән тоташкан була. Әле хәзер дә елгадан су киткән вакытта таш юл калдыклары пәйда була. Нумизматлар йоклап ятмый: иске акчалар эзлиләр һәм табалар. Кызганыч, йокым да тора-бара үз исемен югалта, аны Устье дип атыйлар. Ә татарлар Усия дип җырларда җырлыйлар.

:: «Көмеш дага» маршруты тагын бер елганы – Зөяне дә үз эченә ала. Анда нинди могҗизалар бар?

– Ослан тавы янында Итил, кисәк кенә 90 градуска борылып, көньякка таба ага. Менә шунда төп могҗизага тап булабыз да инде: ике елга – Идел белән Зөя – берберсенә параллель рәвештә агалар, тик аларның юнәлешләре капма-каршы. Бу – дөньяда бердәнбер күренеш, башка мондый урын юк. Зөя елгасының озынлыгы – 375 чакрым, киңлеге 20 метрдан 70 метрга җитә, ә тирәнлеге 0,3 метрдан 4 метрга кадәр. Ул Җигүле ат (Жигули) тау итәгеннән башланып, Сембер (Ульяновск) шәһәре янында Идел елгасына 5 чакрымга кадәр якынаеп, Яңа Әмир (Свияжск) утравы янында Иделгә тоташып, суларын олы елгага куа. Тарихта бу елганың өч исеме билгеле: Сөйям, Зөя, Свияга. Елга бик матур, чиста, балыкка бик бай. Өстән һәм картадан карасаң, бу урын ат дагасын хәтерләтә.

– Димәк, «Көмеш дага» дигән атаманың исеме җисеменә туры килә дигән сүз?

– Әйе. Шул ук вакытта татарлар ат дагасын капкага, йорт диварларына, ишек өстенә кагып куялар. Аны тынычлык, уңыш алып килә, диләр. Ә бу елга буйлары исә – тарихка бик бай, истәлекле, ял итәргә, күңел ачарга уңай урыннар. Мәскәү өлкәсе тирәсендә урнашкан шундый урыннарга сәяхәтчеләрне, туристларны җәлеп итәр өчен, «Золотое кольцо» дигән бренд белән туристик маршрут булдырдылар бит. Мин дә бу урыннарда «Көмеш дага» атамасы белән туристик маршрут бик кулай булыр иде дип уйлыйм. Аның символикасын апамның улы Васыйл ясап бирде. Әле күптән түгел генә оныгым Кәрим: «Бабай, татар атсыз булмый, дага эченә рәсемен ясап куярга кирәк», – дип, аны камилләштерде.

:: Сәяхәтнең маршруты кайларга, туристларны кызыксындырырлык нинди истәлекле урыннарны үз эченә алыр дип күзаллана?

– Бишбалтадан, Адмираллык бистәсеннән башланган сәяхәт, әлбәттә инде, башкаланың Кремлен һәм башка тарихи урыннарны да үз эченә ала. Әйтергә кирәк, һәр тукталышта нинди дә булса кызыклы урыннар инде бүген үк туристларны үзенә җәлеп итеп тора. Исемлекне тулыландырырга гына кирәк. Мәсәлән, Югары Ослан районында – Ярослав Гашек музее, Кызыл Байрак йокымында – Салих Сәйдәшев аланы. Куйбышев затонында, Идел белән Чулман кушылып, 40 чакрым киңлектә ясалган «диңгез» белән ничек хозурланмыйсың ди. Кама Тамагында исә гипс мәгарәсенә сәяхәт күптән оештырылган. Болгар шәһәренә килеп җиткәч, андагы музейлар, тарихи урыннар, тыюлыкның истәлекле урыннарына сәяхәт итү дә бернинди проблема тудырмый. Тәтеш шәһәре йокымына тукталып, 400 елдан артык тарихы булган, Болгар чорында Темтюзи дип аталган шәһәр белән танышырга мөмкин, кырпы балыгына багышланган бердәнбер музей да шунда. Ун дару (Ундоры) шифаханәсе, андагы минераль суларны татып карау сәяхәтчеләргә бер дә комачауламас иде. Ульяновск (Сембер) йокымында исә Владимир Ульянов-Ленин музеена сәяхәт, Александр Керенский турында истәлекләр көтә.

Менә шунда 5–6 чакрым араны үтеп, Зөя елгасына күчү каралган. Арбузов йокымында галимнең тормышы белән танышу, Буа шәһәрендә музейларга, мәчеткә, мишәрләрнең данлыклы театрына сәяхәт итү мөмкинлеге бар. Апас районында исә безне күренекле композиторыбыз Сара Садыйкова музеена сәяхәт көтә. Аннан туристларны Татарстанның иң яшь шәһәре Иннополис белән таныштыра алабыз. Зөя утравындагы Яңа Әмир (Свияжск) шәһәре тарихы белән танышкач, элеккеге татар авылларына күчәргә була. Хуҗа Әхмәт һәм Кызыл Яр авыллары хәзер инде Юдино бистәсенә керә. Анда Ян Юдин музее, Николай Чудотворец чиркәве, «Басу» гольф клубы, Уракчыда танылган татар архитекторы Илдар Ханов төзегән Бөтендөнья диннәре гыйбадәтханәсе бар. Кыскасы, монда язылганнар – программага кертергә мөмкин булганның бер өлеше генә әле.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

1 июнь – Халыкара балаларны яклау көне

КАРИНА МОТЫЙГУЛЛИНА:

«ӨЙ ЭШЕН АЗРАК БИРЕРГӘ КИРӘК»

Казандагы 36 нчы гимназиянең 7 нче сыйныф укучысы Карина Мотыйгуллина «Пятница» телеканалында узган «Умнее всех» тапшыруында катнашкан. «Минем өчен билге түгел, белем мөһим», – ди ул. Башка сыйныфташларына да шуны төшендерергә тырыша. Акыллы укучы белән мәктәп тормышы турында сөйләштек.

«Умнее всех» – дүрт раундлы телевикторина. Анда программалаштыру, шахмат, менталь арифметика һәм башка өлкәләрне белгән укучылар катнаша. Җиңүче суперфиналга чыга.

– Сорауларга җавап бирергә тырыштым. Ләкин ахырдан өч кеше төшеп калды. Алар арасында мин дә бар идем. Кәефем төшсә дә, вакыт үткәч, үземнең Мәскәүгә юкка бармавымны, тәҗрибә туплавымны аңладым. Бер урында гына таптанырга яратмыйм. Әлеге шоуда катнашу миңа алга таба үсәргә ярдәм итәчәк, – дип ышана 13 яшьлек кыз.

Сораулар арасында аптырата торганнары да булган. Әйтик, чыпчыкның умырткалары күбрәкме, әллә жирафныкымы? Карина исә, муены озын булгач, жираф дип җавап биргән. Дөресе – чыпчыкныкы. Шулай ук төрле фильмнардан сюжетлар да тәкъдим ителгән. «Җавап бирә алмасаң, Тина Канделаки: «Син ул киноны карамадыңмыни, белмисеңмени?» – дип әйтеп куя. Андый чакта күңел кырылып китә, әлбәттә. Аның алып баруы бик ошый миңа. Үземнең дә журналист йә алып баручы, актер буласым килә», – ди Карина.

Ул реклама, кинога, тапшыруларга бәйле төрле кастингларда катнашырга ярата икән. Казанда узачак чараларны эзләгәндә, «Умнее всех» тапшыруының белдерүенә юлыккан да инде ул. Август аенда гариза язган. Үзе турында анкета, видео төшереп җибәргән. Көзге каникул вакытында Мәскәүгә чакырганнар. Тапшыру күптән түгел генә эфирга чыккан.

Карина немец, татар, инглиз телләрен өйрәнә, ишарәләр телен белә. Ә менә математика аңа авыррак бирелә икән. Татар телен аңлый, әмма әлегә сөйләшә алмый. «Өйдә татарча сөйләшмибез, әби-бабай булышкалый. 5 нче сыйныфта татар телен туган тел буларак сайладым, каршы килүчеләр дә булды. Туган телдән ничек баш тартасың? Максатым бар, өйрәнермен», – ди ул.

Карина үзен вундеркинд дип санамый. Әмма күп белү теләгән яшерми. Ул үзе «4ле-5ле» билгеләренә укый. Музыка, хореография буенча сәнгать мәктәбен тәмамлаган. Скрипкада уйный. Фәнни китаплар укырга ярата. Соңгы вакытта фәлсәфә белән кызыксына башлаган.

– Замана укучылары соңгы вакытта мәктәптән өйдә укуга күчә башлады. Син дә теләмисеңме? – дип тә сорадык аннан.

– Онлайн уку җиңел. Мәктәпләрдә кайчак кирәкмәгән темалар өйрәтеп, вакытны үткәрәләр. Әйтик, рәсем дәресендә башта озак итеп лекция тыңлыйбыз, аннан ясарга вакыт бик аз кала. Патриотик тәрбия турында сөйлиләр икән, тормышка бәйләп, мисаллар китереп сөйләргә кирәк, – ди ул. – Миндә дә бар иде андый уйлар. Тик аралашу җитмәү файдага түгел. Кеше дөрес итеп аралашырга өйрәнергә тиеш. Менә шул ягы бар.

Репетитор яллауга да каршы түгел ул. Аның әйтүенчә, мәктәптә бер теманы аңламасаң, икенчесен белми каласың. Ә репетитор шуны үзләштерергә булыша. Үзе исә барысын да аңлап укый.

Шул ук вакытта мәктәпләрдә өй эшләре күп бирелүен дә әйтеп узды. Кайчак моның өчен 4–5 сәгать вакыты китә икән. «Дәресләрне 1 сәгатькә сузсыннар, тик өй эшен азрак бирсеннәр иде. Мин министр булсам, беразын киметер идем. Төн буе өй эше эшләү сәламәтлеккә зыянлы. Йокы да бозыла бит. Шуңа күрә программаны үзгәртергә кирәк», – ди әңгәмәдәшем.

Аны чисталык мәсьәләсе дә борчый әле. Мәктәпләргә экология дәресләре кертергә тәкъдим итә. Кайберәүләрнең үз артыннан җыештырмавы, юлга тәмәке төпчекләре, кәнфит, туңдырма кәгазьләре ыргытып калдыруы да ачуын чыгара. Аларга штраф салырга кирәк, ди.

«Безгә кәгазь җыярга кушалар, аны бакча балалары тапшырсын. Югары сыйныфларда пластик әйберләр җыйдыртырга кирәк. Картон тиз чери, ә пластик әйбер таркалганчы мең ел кирәк. Ичмаса, менә шуны аңларга өйрәнерләр, табигатьне пычратмаслар иде», – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 274

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+